ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БӨРЕШЛЕ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

2021 нче елның 21 нче декабрендәге 1 нче номерлы карары

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең
Бөрешле авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., 2004 елның 28 июлендәге 45 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст. нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылы гражданнары җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар, хәрби гамәлләрдә катнашучылардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Җыелган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Бөрешле авылында чокырлы юлларны вак таш җәеп ремонтлау;

2) бензин белән эшләүче кар чистарткычын сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Бөрешле авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бөрешле авыл җирлеге" бүлегендә www.mendeleevsk.tatar.ru, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А. Смирнова